Сибгаева Ф.Р., КДУ

# Бүгенге көн поэзиясендә мәгънәдәш фразеологизмнарның яшәеше

Шигырь – аваз һәм иҗекләр матур яңгырашлы итеп билгеле бер тәртипкә салынган сөйләм. Шигърият ул – туры мәгънәдә әйтеп түгел, бәлки күчерелмә сурәтлелек аша күңелдә канәгатьләнү тойгысы уята торган сәнгать телләренең берсе.

Татар теленең үз кануннарыннан килеп чыккан шигырь системасы – ул силлабика. Ягъни һәр шигырь юлы билгеле иҗек күләмендә алына, ә ул шигырь юлларын исә буйдан-буйга шулай ук билгеле сандагы иҗекләр төркеменнән соң цезуралар үтә. Хәзерге көндә иң еш кулланыла торган шигырь үлчәме – дүртенче (яки сирәк очракта өченче) иҗекләрдән соң цезуралы (яки бөтенләй цезурасыз) сигез дә җиде үлчәмле шигырь. [Курбатов Х.Р., 2002, 6]

Поэзиядә фразеологизмнар - сурәтләү чаралары арасында поэтик стильнең кирәкле өлешләренең берсе. Аларның теге яки бу язучы тарафыннан кулланылуын тикшерү  язучының индивидуаль иҗат методы үзенчәлекләрен ачу өчен мөмкинлек бирә.

Фразеологизмнарның стилистик үзенчәлекләрен, эмоциональ-экспрессив характерларын тирәнрәк ачу өчен, аларны составы ягыннан да, лексик-семантик үзенчәлекләре ягыннан да тикшерергә мөмкин. Гадәттә аларны түбәндәгечә бүлеп карыйлар:

1. Фразеологик синонимнар;
2. Фразеологик омонимнар;
3. Фразеологик антонимнар;
4. Фразеологик гиперболалар.

Бу төр фразеологизмнар хәзерге татар поэзиясендә гаять актив. Аеруча фразеологик синонимнар күп кулланыла.

Күп кенә тотрыклы сүзтезмәләр вакытлар узу белән үзләренең беренчел образлы мәгънәләрен югалталар. Бу төр “бушлыкны” поэзиядә контекстуаль яңарту ысуллары белән тулыландыралар.

***Фразеологик синонимнар*** — ул аваз формасы ягыннан төрле, ә мәгънәләре буенча тәңгәл яки бик якын булган тел берәмлекләре. Алар теге яки бу мәгънә (яки стиль) төсмерен аерган вакытта кулланылалар. [Поварисов С.И., 2003, 93] Әдәби әсәрләрдә бер үк фикернең берничә тапкыр кабатлануы юкка түгел, образлылык, сәнгатьлелек, эмоциональ-экспрессивлылык тудыру өчен кирәк.

Татар тел белемендә фразеологизмнарны төркемләүдә карашлар төрлелеге булган кебек үк, алар арасындагы синонимлыкны билгеләүдә дә фикерләр байтак.

Татар һәм рус тел белемендә киң таралган бүленешне тикшерүнең нтгезе итеп алырбыз

Н.М. Шанский, В.Н. Клюева, Ә.А. Ахунҗанов, Н.Ш. Ханбикова фразеологизмнардагы синонимлыкның 3 төрен билгелиләр:

1. Сүз һәм фразеологик берәмлекләр синонимлыгы (фразеологик берәмлек сүзгә караганда һәрвакыт диярлек образлырак һәм экспрессиврак була; күпчелек очракта, сүзләргә карата образлы аныклагыч функциясен үти; фразеологизмнар сүзләрдән грамматик күрсәткечләре белән аерылырга мөмкин).

2. Фразеологизмнарның үз эчендә синонимлыгы.

3. Сиононим вариантлар:

1) бер яки берничә компонентын гомумтел яки контекстуаль синонимнар белән алыштыру;

2) фразеологизмның компонентлар составын киңәйтү яки кыскарту;

3) бер үк вакытта компонентларын алыштыру һәм составларын үзгәртү.

Тикшерү объекты итеп соңгы елларда поэзия өлкәсендә актив иҗат иткән Зөлфәт, М. Әгъләмов, Р. Фәйзуллин, Ф. Тарханова, Р. Рахман, Н. Измайлова шигырьләре алынды.

Поэзиядә сүз һәм фразеологик берәмлекләр арасында синонимлык күренеше актив булуы күзәтелде. Шагыйрьләр, мондый төр берәмлекләрне бер үк җөмлә эчендә һәм сүз аңлата торган күренешкә тулырак характеристика бирү өчен кулланалар. Мәсәлән,

*Ямьсез* күреп ямьсез дия күрмә -

Һәр чәчәкнең аның төсе бар.

**Сөйкемсез сөяк** буламы! –

Һәркемнең әнисе бар. [Измайлова Н., 2003, 178]

Н. Измайлова **ямьсез** сүзенең мәгънәсен тагын да ача торган, үтемлерәк итә торган "сөйкемсез сөяк" дигән фразеологик мәгънәдәш вариантын куллана. Әлеге тотрыклы сүзтезмә сыйфатны тулырак, үтемлерәк итә.

Бүген ил эзләп ятулар

Чын-чынлап *чиләнүдер,*

Һәм **тишексез иләк аша**

**Әкияти иләнүдер**. [Әгъләмов М., 2003, 54.]

Шагыйрь чиләнүне тишексез иләк аша әкияти иләнү белән тиңли һәм синонимик варианты буларак тәкъдим итә.

Зөлфәт **яшәү** сүзенә мәгънәдәш итеп "дулкын килү" фразеологик берәмлеген куллана:

... Исән чакта

"*яши*", димәсеннәр.

"Нинди **дулкын килә**!" – дисеннәр. [Зөлфәт, 2003, 170]

Фразеологик берәмлекләрнең үз эчендәге синонимлыкны Ш. Ханбикова: "Боларның сүз эквивалентлары юк, ягъни, бу төшенчәләр аерым сүз белән түгел, ә сүз тезмәләре аша гына белдереләләр", - ди. [Ханбикова Ш.С., 1980, 56]

Бу төркемгә керә торган фразеологик берәмлекләр поэзия теленең байлыгын, матурлыгын күрсәтә. Әлеге төркемдә гомумтел, ягъни,

сүзлекләргә теркәлгән фразеологик берәмлекләрдән тыш, шагыйрьләр үзләре иҗат иткән, индивидуаль тотрыклы сүзтезмәләр дә күпләп урын ала.

*Яшәү* сүзенең мәгънәсен шагыйрьләр шигырь текстында **канат җәю; тиле дулкын белән кушылу; илне тарту; чишмә булып кушылып, инеш булып бергә агу; көн итү; үз кул көче белән байлыкка тиенү; фани дөнья йөген җигелеп тарту; астан агу** һ. б.

Катламнардан актарылып чыгып

Бер-беребезне эзләп табабыз.

Тын үзәндә сихри кич булганда

**Чишмә булып сиңа кушылам да**

**Инеш булып бергә агабыз**. [Әгъләмов М., 2003, 48.]

...Хаклысың, юлдаш!

Күргән һәм

**Көн иткән** дәвереңдә

Уйлаган уйга иңә шул ... [Зөлфәт, 2003, 170]

Безгә башлау кирәк

Бүген...

**Җигелеп тарту** өчен **фани**

**дөнья йөген**. [Әгъләмов М., 2003, 48.]

Бозлар каплап киткән фасылда да

**Астан** гына барыбер **агабыз**. [Әгъләмов М., 2003, 48.]

Шулай ук фразеологик синонимнар күпләп хәтер, өмет һәм өметсезлек, көрәш, аптырау, борчылу, вафат булу кебек сүзләрнең мәгънәләрен ачуда кулланылганнар. Мәсәлән, *өметләнү* – **язмыш елмаюын көтә-көтә; өмет йөртү; өметләр көмәндә булу; күккә ашу; хыяллар күтәрелү һ. б.; үлү – җан бирү; гомер көзенә җитү; янган утка атылу; кылыч чабу; төпсез күккә ыргу; дулкын барып ауган ярга барып аву; җан тәслим кылу** һ. б.; *хәтер һәм хәтерләү* – **искә килү; уйга иңү; җырлаган җырга иңү; салынган эзләр; күңелгә моң булып утыру; йөрәккә салу һ. б.;** *өметсезлек* – **кулдан эш төшү; җанда җылы булмау; өмет киселү;**

**җанның утын сүндерү; кара таң уяну; офыкта кара кояш бату; өмет әвененнән егылып төшү** һ. б.; *борчылу* – **җанга тию; йөрәк кагу; җан кыю; канга тию** һ. б.  бик күп мгънәдәш фразеологик синонимнарны атап үтәргә мөмкин.

Мондый төр фразеологик берәмлекләр М. Әгъләмов иҗатында күпләп очрады. Әлеге күренеш автор теленең камил, бай, сыгылмалы булуы хакында тагын бер тапкыр ассызыклый.

Өченче төркемгә керә торган тотрыклы сүзтезмәләрнең күпчелеген шагыйрьләр, әдәби телдә булган һәм сүзлекләргә теркәлгән фразеологик берәмлекләрне иҗади үзгәртеп, шигърияттә образлы гыйбарә буларак кулланалар. Чөнки шигъриятнең үз закон-кануннары бар: ритм, рифма, шигъри үлчәм, ә шагыйрьгә тотрыклы сүзтезмә аша мәгънәне шигырь калыбына урнаштырып бирергә кирәк, шул сәбәпле фразеологизмнарның структурасы текстта үзгәреш кичерергә мәҗбүр була. Мәсәлән,

**Кеше кесәсенә кермәү** фразеологик берәмлегендә Зөлфәт **кермәү** компонентын **төшмәү** гомумтел синонимы белән алыштырып бирә:

Син, энекәш, салып җибәр әле...

Иснәп җибәр аннан бүрекне!

**Төшмибез** ич **кеше кесәсенә** —

Без бит ... шуның белән иректе! («Аңлатыр хәлләрем юк». — Б. 275.)

Мөдәррис әгъләмов исә, кабатлаудан качу һәм сүз уйнату максатыннан, **йозак салу** һәм **тозак салу** кебек контекстуаль синонимнар куллана.

Келәтләргә **йозак салынды**,

Чибәрләргә **тозак салынды**.

(Әгъләмов М., 2003, 162)

Үлү мәгънәсен бирә торган **җан тәслим кылу** фразеологик берәмлеген Зөлфәт шигъри үлчәмгә туры китереп, “җан тәслим” формасында гына куллануны кирәк таба:

Инде **җан тәслимең** көнендә

Күкрәгеңә башкаемны куеп,

Маңгаеңнан сыйпар идем дә... [Зөлфәт, 2003, 169]

**Күктән бәхет төшү (яву)** тотрыклы сүзтезмәсен Зөлфәт “Язмыш” шигырендә, экспрессивлыкны арттыру, төгәлләштерү һәм шигъри үлчәмгә туры китерү максатыннан, структур компонентларны киңәйтеп куллана:

... Күзләргә дә барып кердек инде...

**Ак бәхетләр күктән төшмәде**, -

Ул бәхетне сары яфрак итеп

Җилле көзләр алга түшәде... [Зөлфәт, 2003, 162]

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, Зөлфәт фразеологик синоним вариантларны куллануны кулайрак күрә.

Күзәтүләрдән чыгып? шуны искәртеп үтәргә кирәк: шигърияттә фразеологизмнарны ир-ат шагыйрьләр күпләп куллана. Әлеге күренешне ир-атларга хас булган үзенчәлек – бер-ике сүзгә тулы бер мәгънә сыйдыра алу сыйфаты белән бәйләп карарга кирәктер. Поэзиядә фразеологизмнар бик сирәк вакытта гына үзгәртелмичә кулланыла, һәр яңа шигырь иҗат ителгән саен, кимендә, яңа бер фразеологик синоним туа. Фразеологик синонимнар барлыкка килү, поэзия телендә иң актив процессларның берсе булып кала бирә.

## Әдәбият

1. Ахунҗанов Г.Х. Татар теленең идиомалары/Г.Х. Ахунҗанов. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1972. — Б. 56.

2. Бакина М.А. Структурно-семантические преобразования фразеологических единиц в современной поэзии//Лингвистические заметки/М.А. Бакина. — №3. — 1982. — С. 70.

3. Курбатов Х.Р. Шигырь энҗеләре ничек барлыкка килә/Х.Р. Курбатов. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 6.

4. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология / Ф.С. Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 1999. – 253 б.

5. Ханбикова Ш.С. Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр / Ш.С. Ханбикова. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. – 256 б.

**Чыганаклар**

1. Татар шигърияте. – Казан: Мәгариф, 2003. – 254 б.
2. Әгъләмов М.З. Иман тәрәзә шакый: Шигырьләр. Балладалар, поэмалар / М.З. Әгъләмов. — Казан: Тат. кит. Нәшр., 1996. — 335 б
3. Татар поэзиясе антологиясе. 1 нче китап. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1992. — 545 б
4. Татар поэзиясе антологиясе. 2 нче китап. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1992. — 512 б.
5. Фәйзуллин Р. Сайланма әсәрләр. Т.1 / Р. Фәйзуллин. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1992. — 415 б.
6. Фәйзуллин Р. Сайланма әсәрләр. Т.2 / Р. Фәйзуллин. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. — 502 б.